# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**02.09.2024 ел** **№ 6**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башлыгының 22.08.2024 елгы 4 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2024 елның 18 мартындагы 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 18.03.2024 № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 18.03.2023 № 2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Урсай авылында лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр);

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(Урсай авылында килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларын алыштыру);

3)торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Урсай авылында юлларны профильләштерү, Үзәк урамда гравий япма урнаштыру һәм юлларны кардан чистарту);

4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылының Совет урамында «Брусчатка» тибындагы бетон плиткадан түшәү, эскәмияләр сатып алу, урнаштыру)».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урсай авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге Башлыгы З.Х.Рахимьянова